# *Ач, шигърият, серләреңне*



## Кодашым

«Кодашым” дисәм күз алдымда
Гаҗәеп яшел таулар,
Елгасына сакчы сыман
Торучы биек ярлар.

Уйсу җирдә күкрәп үскән
Шул чаклы бәдрә таллар!
Таулар аша офыклардан
Чакыра алсу таңнар.

“Кодаш”дисәм үргә менәм,
Таулар өстендә урман,
Урман эче печән, җиләк...
Бәрәкәт белән тулган.

Чыксам басу-кырларыңа
Салкын чишмәләр күрәм.
Сусавымны басар өчен
Шул чишмәләргә киләм.

Авылым тора күз алдымда
Таудан карагач менеп.
Гел кайтып-күреп торсам да,
Һаман сагынам кебек.

Әхәт Галләмов



**Сынатмады татар егетләре**

Кырык бердә кара болыт кебек,
Басып керде фашист илләргә.
Кичекмәстән без дә күтәрелдек,
Соры шинель салып иңнәргә.

Туган илнең аяз күк йөзендә
Бомбовозлар очты үкереп.
Соры шинель кигән солдат егет
Бруствергa менде сикереп.

Сынатмады татар егетләре,
Батырларча утка керделәр.
Курку белмәс арысланнар кебек
Фашистларны тетеп йөрделәр

Истән чыгармагыз батырларны,
Даны китсен ерак илләргә.
Һәйкәл булсын сезгә шигъри сүзләрем,
Яуда үлгән батыр ирләргә.

Заһит Әхмәтшин



**Хәтердә әле**

*(Ватан сугышы инвалиды*
*Калимулла бабайга багышлана)*

Яңа мәчет тыкрыгы , чирәмлектә
Аксакаллар тезелеп утырган.
Көтәләр күк муллаларын гына
Матур итеп Көрьән укырга.

Колаклары инде ишетми дә,
Күзләр инде күптән күрмиләр,
Үткән гомерләрен искә алып,
Картайдык дип сыкрап йөрмиләр.

Исләрендә әле: яу кырларында
Арысландай сугышып йөргәннәр,
Фашистларның җанын тетә-тетә,
Берлингача барып җиткәннәр.

Күкрәге дә тишек штык белән,
Аяк-куллар тулы җәрәхәт...
Шулай аны сугыш яралаган,
Нык кыйнаган сугыш – кабахәт.

Бозлы окопларда туңган чакта
Тыны белән затвор эреткән.
Шундый вакытта да бирешмәгән,
Дошманнарга кургаш йөгерткән.

Заһит Әхмәтшин





**Яз җилләре**

Апрель ае, язгы җилләр улый,
Карны куа, өзә – кискәли.
Ә карт солдат авыр ярасыннан
Йоклый алмый, нидер исәпли.

Тәнендәге яралары сызлый,
Тынгы бирми, һәрчак кисәтә.
Узган гомер авырлыгы белән
Һич онытылмый, бар да исәптә.

Тау битләре кардан ачылалар,
Борын төртә яшел үләннәр.
Әле һаман йөрәк өзелеп көтә
Кайтыр сыман яуда үлгәннәр.

Алар үлмәделәр - истә алар.
Халкыбызның асыл уллары.
Мәңге истә сакланырлар алар
Күз алдында –йөргән юллары.

Заһит Әхмәтшин



## Язлар килә

Матур язлар тагын килде,
Җилкендереп тузган йөрәкне.
Язгы матурлыклар баса алмый
Истә йөргән изге теләкне.

Әйтми калу үзе зур гөнаһтыр
Шушы матур язгы көннәрдә,
Башын иеп сәлам юллый кебек
Юл буенда үскән гөлләр дә.

Чын күңелдән сәлам сезгә,
Кайтмый калган батыр ирләргә.
Йөргән юлыгызны чәчәк бизи,
Таралдыгыз төрле җирләргә.

Йөрәгемнең тирән упкынында
Саклanасыз. Туган иллəрдән
Сезгә бездән сәлам юлласыннар
Моңсу искән язгы җилләр дә.

Истән чыгармабыз сезне,
Безнең белән бергә булырсыз.
Бәйрәм көннәрендә дога кылып,
Сагынып-сагынып искә алырбыз.

Заһит Әхмәтшин



## Җир уллары

Бер әйләнеп кара, дустым,
Җир ананың гүзәллегенә.
Үзеңнең дә исең китәр
Җир ананың түземлегенә.

Сокланмыйча мөмкин түгел,
Безне яшәтүче җир бит ул.
Җиргә хуҗа булып яшәүче дә,
Буразнада үскән ир бит ул.

Җир ананы яратырга кирәк,
Уйлап эш итәргә һәр чакта.
Җир уллары моны яхшы белә,
Истән чыгармаска кирәк бу хакта.

Заһит Әхмәтшин



**Кайтмадылар алар әйләнеп**

Көнбагыштан кара болыт басты,
Сайрар кошлар тынып калдылар.
Әти-абыйларны бик тиз генә
“Военком”га чакырып алдылар.

Күпләр әле онытмаганнардыр
Чабаталы “Союз” солдатын.
Башлар ниләр генә күрсәләр дә,
Онытмады һәркем үз антын.

Яланаяк стройга басып,
Суслонгерда агач ташулар,
Истә әле, һаман истә әле,
Туң бәрәңге җыйган басулар.

Кайтмадылар әти-абыйларым,
Кай җирләрдә башны салдылар?
Геройларча алар шәһит булып,
Мәңгелеккә ятып калдылар.

Солдат окопларын үлән баскан,
Эзләре дә инде билгесез.
Әти-абыйларның батырлыгы
Алар истә – алар үлемсез!

Заһит Әхмәтшин



**Яз җилләре хәбәр китерә**

Салкын кыш та артык озын түгел,
Һәм бирешә ул язгы җилләргә.
Күп бәхетләр, үзгәрешләр көткән
Ни китерер эшчән ирләргә!

Җир уллары батыр игенчеләр
Зарыгып көтә язның килүен.
Һәм, Ходайдан сорап, мул уңышлар
Теләп йөри алар бирүен.

Язгы җылы матур көннәрдә-
Сабан тургайлары сайрый күкләрдә.
Зур өметләр белән яши игенчеләр.
Сәламәтлек бирсен Ходай күпләргә.

Тургайларның моңлы сайраулары
Кемнең генә күңелен күтәрми,
Шушы матурлыкны тойган кеше
Туган авылын ташлап китәрме!?

Яшиселәр килә якты дөньяларда,
Ду китереп эшләп сукада.
Үз халкына бәхет китерерлек
Эшләр эшләп йөреп булса да.

Заһит Әхмәтшин



**Кыш килде**

Салкын кыш та килде
Бураннары белән...

Урманнар да ак киемгә төренделәр,
Әйтерсең лә туй күлмәге кигән кыздай.
Барча кеше хәйран кала, сөенделәр
мондый гүзәллеккә
Сөенмичә мөмкин түгел – түзәрлек тә.

Ә кыш бабай үзенең эше белән
Ду китереп йөри урманнарда.
Ашыга-ашыга бүләк җыя капчык-капчык
Бәйрәмдә өләшергә балаларга.

Иртән торуга кар таулары өйгән,
Ай-һай гайрәт-көчле Кыш бабабыз!
Чаналарны сөйрәп кар тавына ашыгабыз,
Рәхәтләнеп Кыш бабайга булышабыз.

Яңа елга кыш бабакай килеп җитә,
Үзе белән кар кызын да алып килә.
Зур капчыгын күтәргән дә җилкәсенә,
Ашыга ул бүләкләрне балаларга җиткезергә.

Заһит Әхмәтшин



**Хәтердә саклана**

*(Сугыш чорында Суслонгер лагерьларында хезмәт иткән солдатларга багышлыйм)*

Әкияти кара урманнары,
Сазлыкларга баткан юллары...
Бу җирләрдә күпме җәфа чикте
Халкыбызның асыл уллары.

Нарат ылысының суын эчеп
Йөрәкләргә хәлләр керәме?
Җилкәләрдә агач ташыганда
Туган яклар искә киләме?

Карап торуга ук шомлы монда,
Эт тә йөрмәс мондый сазлыкта,
Каберләргә кемнәр күмелмәгән-
Баш очында юк бер казык та.

Яуга чыгып киткән чакта ирләр
Күз яшьләре тамды юлларга.
“Исән йөреп, тизрәк кайтыгыз!”-дип,
Дога кылып калдык шуларга.

Хәтер бүген үткәннәрне барлый:
“Сез кайларда, нишләп ятасыз?”
Язлар килгән саен тагын бергә
Яу кырларын урап кайтабыз.

Заһит Әхмәтшин